ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар 2014 ел Казан шәһәре № 10-1/кс

***"Светсервис" МУП тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифларны билгеләү турында***

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында" 07 декабрь 2011 ел, № 416-ФЗ Федераль законы нигезендә, "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салу" 13 май 2013 ел № 406 Россия Федерациясе карары, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. "Светсервис" МУП тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифларны, календарь бүленеш нигезендә, түбәндәге карарның кушымтасына туры китереп билгеләргә.
2. Түбәндәге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 01 мартыннан 2014 елның 31 декаберенә хәтле үз көченә ия була.
3. Россия Федерациясе Хөкүмәте 17 гыйнвар 2013 елгы, № 6 карары белән расланган, иректе кулланышка кертелергә тиешле, су белән тәэмин итү һәм һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә информацияне ачу стандартларына нигезләнеп, МУП "Светсервис" алдагы җайга салу чорына тарифларны билгеләү турында нәтиҗәгә килгәч, 30 календарь көннән дә соңга калмыйча информацияне ачырга.
4. Түбәндәге карар рәсми нәшер ителгәннән соң ун көн узгач тулы көченә ия була.

Татарстан Республикасы
тарифлар буенча
дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитеты карарына
кушымта
24 гыйнвар 2014 ел № 10-1/кс

МУП "Светсервис" тарафыннан тапшырылган, кайнар су белән тәэмин итү ябык системалары өчен, календарь бүленеш нигезендә алынган кайнар су тарифлары

| № п/п | Муниципаль берәмлек, кайнар су белән тәэмин итүче оешма исеме | Кайнар су белән тәэмин итү ябык системаларында кайнар су тарифлары (ике компонентлы) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Салкын су компоненты, сум./куб.м | | Җылылык энергиясе компоненты, сум./Гкал | |
| | | 01.03.2014 алып 30.06.2014 кадәр | 01.07.2014 алып 31.12.2014 кадәр | 01.03.2014 алып 30.06.2014 кадәр | 01.07.2014 алып 31.12.2014 кадәр |
| | Әлмәт муниципаль районы | | | | |
| 1 | МУП «Светсервис» | | | | |
| 1.1 | Торак секторы кулланучылары (тарифларда ӨБС исәпкә алынган )* | 39,05 | 39,72 | 1990,29 | 2088,22 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифларда ӨБС исәпкә алынмаган) | 33,09 | 33,66 | 1686,69 | 1769,68 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәнең 6 пунктын тормышка ашыру максаты белән аерып алына

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге